Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы
Мәмәшир авыл җирлеге башлыгы

# КАРАР

11 февраль, 2026 ел № 1

Мәмәшир авыл җирлеге чикләрен Киров өлкәсе чиге белән чиктәш җирдә Татарстан Республикасы чигенә туры китерү буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы «Мәмәшир авыл җирлеге» Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы «Мәмәшир авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге халкының «Мәмәшир авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләрен туры китерү турындагы мәсьәләне гавами тыңлаулар уздыру юлы белән тикшерүдә катнашу хокукларын үтәү максатларында

КАРАР БИРӘМ:

1. 1. Кушымта нигезендә Кукмара муниципаль районы Советының 2025 елның 7 ноябрендәге 20 номерлы карарында белдерелгән Мамашир авыл җирлеге чикләрен Киров өлкәсе чиге белән чиктәш җирдә Татарстан Республикасы чигенә туры китерү инициативасын карау турында гавами тыңлаулар үткәрүне 2026 елның 2 мартына билгеләргә.

2. Гавами тыңлауларны үткәрү урыны итеп, Мәмәшир авыл җирлеге башкарма комитеты бинасын билгеләргә, адресы: Татарстан Республикасы, Кукмара районы, Мәмәшир авылы, Яшьләр урамы, 29б йорт. Үткәрү вакыты: 09 сәгать 00 минут.

3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән мәсьәлә буенча гавами тыңлауларны билгеләнгән тәртип нигезендә һәм әлеге карарда билгеләнгән срокларда оештыру һәм уздыру буенча түбәндәге составта эшче төркем төзергә:

Әхмәтҗанов Илгиз Габтеләхәт улы – ТР Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге башлыгы

Насыйбуллин Ринат Раян улы – ТР Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге Советы депутаты;

Вәһапов Фәрит Вәгыйзь улы – Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге Советы депутаты;

Шаһиев Илшат Илһаметдин улы – ТР Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге Советы депутаты

Шәяхкәмов Хәмит Котдус улы – ТР Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге Советы депутаты.

4. Фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын уздыру барышында идентификацияләнгән гавами тыңлауларда катнашучылардан язма яисә телдән, язма формада авторның ФИА һәм аның адресын күрсәтеп, Мәмәшир авыл җирлеге администрациясе адресына (Татарстан Республикасы, Кукмара районы, Мәмәшир авылы, Яшьләр ур., 29Б й.) (2026 елның 11 февраленнән 2026 елның 2 мартына кадәр эш көннәрендә 09:00 дән 16: 00 гә кадәр) яисә Mam.kuk@tatar.ru электрон адресына кабул ителә.

5. Гавами тыңлауларда чыгыш ясау хокуккы белән катнашу өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча бирелә: Татарстан Республикасы, Кукмара районы, Мәмәшир авылы, Яшьләр урамы, 29б йорт, шәхсән яисә почта аша (конвертта «гавами тыңлаулар» тамгасы белән), 884364-36604.

6. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Мәмәшир авыл җирлеге башлыгы И.Г.Әхмәтҗанов

ОГРН 1021607753012
ИНН 1623001702

Мәмәшир аавыл җирлеге башлыгының
2026 елның 11 февралендәге карарына
1 нче кушымта

